| | **иҗатына кыскача күзәтү.**«Әнкәй», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...» шигырьләре. Лирик жанр - күңел лирикасы. Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Тезмә сөйләм үзенчәлекләре.<br>**Ә.Еникинең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Әйтелмәгән васыять» хикәясе.Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче геройлар, җыелма образлар. Персонаж, характер, тип. Хикәяләүче, автор образы, автор позициясе.<br>**Ш.Хөсәеновның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Әни килде» драмасы. Драма төренең драма жанрына хас үзенчәлекләр. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әдәби иҗат. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция).<br>**Г. Сабитовның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Тәүге соклану», “Ярсулы яз” хикәяләре. Композиция: әсәр кору алымнары. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья.<br>**М.Мәһдиевнең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Без кырык беренче ел балалары» повесте. | тәрбия мөмкинлекләреннән файдалану | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Хикәяләүче, автор образы, автор позициясе. Әсәрнең геройлары. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция).<br>**М.Галиевның тормыш юлына кыскача күзәтү. “Уйна әле” хикәясе.** Эпик жанрлар турындагы белемнәрне киңәйтү. Әдәби әсәрдәге образлылык. Тема, проблема, идея. Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре**.**<br>**Г.Гыйльмановның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Язмышның туган көне» хикәясе. Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Конфликт, сюжет, сюжет элементлары.<br>**З.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Сәер кыз» драмасы. Драма төренең драма жанрына хас үзенчәлекләре. Тема, проблема, идея. Идеал. Сәнгати алымнар һәм стиль.<br>**Р.Харисның тормыш юлына кыскача күзәтү. «Сабантуй» поэмасы.** Лиро-эпик жанр - поэма. Лирик һәм эпик төр сыйфатларының поэма жанрында чагылышы. Персонаж, характер. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Милли бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр.<br>**Р. Фәйзуллинның тормыш юлына кыскача күзәтү.** “Биеклек”, “Туган тел | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | турында бер шигырь” әсәрләре, лирик жанрларны тану күнекмәсен үстерү, лирик герой сыйфатларын билгеләү. | | |
| **Барысы** | | | 34 |

**Календарь-тематик план.**

| Дәрес № | Темалар | Укучыларның эшчәнлеге | Үтәлү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| 1 | Сәнгать төре буларак әдәбият.<br>Халык авыз иҗатының бер жанры буларак дастан.<br>«Идегәй» дастаны | Укылган текстның эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, төп билгеләмәләрнеязып бару.<br>Анкета сорауларын анализлау, таблица тутыру, фольклор әсәрләренең жанрын һәм аларга хас үзенчәлекләрне таба белү, дастанны уку | 7.09 | |
| 2 | “Идегәй” дастаны. Идегәй һәм Туктамыш образлары. | Сорауларга җавап бирү, таблица тутыру, дастанны уку, әңгәмәдә катнашу.<br>Ятлаган өзекне сәнгатьле сөйләү, сорауларга җавап, образларга характеристика бирү. | 14.09 | |
| 3 | XX гасыр башы әдәбияты. Г.Тукай. «Милләтә», “Милли моңнар”, “Өзелгән өмид”,“Шагыйрь”. “Театр”шигырьләре Гражданлык лирикасы,автор позициясе төшенчәләре. | Укылган текстның эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, план-конспект төзү.<br>Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, шигъри текстларны яттан сөйләү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын аера белү;. фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу. Гражданлык лирикасы, автор позициясе төшенчәләре турында мәгълумат алу. | 21.09 | |
| 4 | БСҮ.“Милли моңнар” шигырен сәнгатьле сөйләү. “Минем милләтем –минем горурлыгым”инша язу | Сәнгатьле сөйләм. Иҗади эшчәнлек: әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле укып; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле фикерләрне язмача бирү, әдәби әсәрне тормыштан алган фикер-карашлар, хис-кичерешләр белән бәйләп сочинение язу. | 28.09 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | Н.Думави. «Яшь ана» хикәясе.<br>Образлар системасы. | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу,<br>язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләү; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, план төзи белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; хикәя жанры үзенчәлекләрен әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, кеше<br>образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар күрә, аера белү. | 5.10 | |
| 6 | Ш.Камал. «Акчарлаклар» повестен өйрәнә башлау. | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу; укыган әсәр эчтәлеге буенча терәк схема, план төзи белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; жанр үзенчәлекләрен<br>билгели белү; әдәби әсәрдәге образлылык, образ, символ, деталь, аллегория, табигать образы, әйбер образы, пейзаж, портрет,<br>психологизм. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт образы (хронотоп) һ.б.күрә,<br>аера белү. | 12.10 | |
| 7 | Ш.Камал. «Акчарлаклар» әсәренә анализ. | | 19.10 | |
| 8 | Ш.Камал. «Акчарлаклар». Повесть жанры. Образлар системасы. | | 26.10 | |
| 9 | 1920-1930 еллар әдәбияты.<br>Һ.Такташ“Мокамай” поэмасы.<br>Һ.Такташ“Мокамай” поэмасына анализ | Укылган текстның эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, план-конспект төзү.Тест эшләү.<br>Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, шигъритекстларны яттан сөйләү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештәҗавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын аера белү;. фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу, әдәби әсәрне сюжет–композиция, образлар бирелеше, тел–стиль ягыннан анализлау,сәнгатьле сөйләм. Лирик һәм эпик төрсыйфатларының поэма жанрында чагылышы. Персонаж, характер. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт.Текст: эпиграф, багышлауны таный алу. | 9.11 | |
| 10 | Г.Исхакый. «Җан Баевич» комедиясе (1-2 пәрдә) | Комедия жанрын һәм аңа хас үзенчәлекләрне тану, әдәби әсәр төрләрен,жанрларын таный, аера, аларга хас үзенчәлекләрне таба белү, фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу. Драма әсәрләрен аңлы һәм сәнгатьле укый белү; укыганны телдән | 16.11 | |
| 11 | Г.Исхакый. «Җан Баевич» комедиясе(3-4 пәрдә) | | 23.11 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12 | Г.Исхакый «Җан Баевич»комедиясен өйрәнүне йомгаклау. | сурәтләп бирә алу.Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция) турында төшенчә алу. | 30.11 | |
| 13 | Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” повестен өйрәнә башлау. | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу; укыган әсәр эчтәлеге буенча терәк схема, план төзи белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; жанр үзенчәлекләренбилгели белү; әдәби әсәрдәге образ, символ, деталь, аллегория, эчтәлек:вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. тема, проблема, идея,пафос. һ.б.күрә, аера белү.Эпик жанрлар турындагы белемнәрнекиңәйтү. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ,деталь, аллегория. Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. | 7.12 | |
| 14 | Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр”. Дуслашу. Таралышу | | 14.12 | |
| 15 | Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” повестена анализ. | | 21.12 | |
| 16 | БСҮ “Чын дус-сыналгандус”, “Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен” темаларына инша(теманы сайлау ирекле) | Иҗади эшчәнлек: төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле укып; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле фикерләрне язмача бирү, әдәби әсәрне тормыштаналган фикер-карашлар, хис-кичерешләр белән бәйләп сочинение язу. | 28.12 | |
| 17 | XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты. С.Хәким «Бу кырлар, буүзәннәрдә..., .«Әнкәй» шигырьләре ДТУ С.Хәким. “Дәверләр капкасы” | Укылган текстның эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, проблемалысорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, план-конспект төзү. Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, шигъритекстларны яттан сөйләү; эзләнү эшчәнлеге: проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын аера белү;. фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу.Лирик жанр-күңеллирикасы. Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Тезмә сөйләм үзенчәлекләрен билгели белү. Поэманың эчтәлеге белән танышу. Проблемалы сорауларга җавап табу, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын аера белү;. фикерләрне раслауөчен әсәрдән дәлилләр таба алу. | 11.01 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 18 | Ә.Еники. «Әйтелмәгән васыять» хикәясе. | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләү; укыган әсәр эчтәлегекатламнарына бәйле терәк схема, план төзи белү; эзләнү эшчәнлеге: проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, әсәр композициясе үзенчәлекләренкүрә, аера белү.Әдәби әсәрдәге образлылык.Образ,символ, деталь, аллегория. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче геройлар, җыелма образлар. Персонаж, характер, тип. Хикәяләүче, автор образы, автор позициясен билгели алу. | 18.01 | |
| 19 | Ә.Еники. «Әйтелмәгән васыять» хикәясе. Ялгыз үткән картлык. Акъәби образы. | | 25.01 | |
| 20 | Ә.Еники. «Әйтелмәгән васыять» хикәясен өйрәнүне йомгаклау. | | 1.02 | |
| 21 | Ш.Хөсәенов. «Әни килде» драмасы. Драма төре һәманың жанрлары. | Жанрны һәм аларга хас үзенчәлекләрне тану, әдәби әсәр төрләрен, жанрларын таный, аера, аларга хас үзенчәлекләрне таба белү, фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу. Драма әсәрләрен аңлы һәм сәнгатьле укый белү; укыганны телдән сурәтләп бирә алу.Драма төренең драма жанрына хасүзенчәлекләр. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әдәби иҗат. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция) билгели алу. | 8.02 | |
| 22 | Ш.Хөсәенов. «Әни килде» драмасы. | | 15.02 | |
| 23 | Ш.Хөсәенов. «Әни килде»драмасын өйрәнүне йомгаклау. БСҮ “Әнием – бәгырем”темасына инша язу | Иҗади эшчәнлек: төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле укып; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле фикерләрне язмача бирү, әдәби әсәрне тормыштаналган фикер-карашлар, хис-кичерешләр белән бәйләп сочинение язу. | 22.02 | |
| 24 | Г. Сабитов. «Тәүге соклану» һәм “Ярсулы яз” хикәяләре | Әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле уку; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, плантөзи белү. проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, композиция: әсәр кору алымнарын күрә, аера бел; тема, проблема,идея, пафос, вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст, конфликт, сюжет, сюжет элементларын дөрес билгеләү. | 29.02 | |
| 25 | М.Мәһдиев. «Без кырык беренче ел балалары» повестен | Әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле уку; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, плантөзи белү. проблемалы сорауларга | 7.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | өйрәнә башлау | мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, әсәр композициясеүзенчәлекләрен күрә, аера белү.Хикәяләүче,авторобразы, автор позициясе. Әсәрнең геройлары. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәбиалымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция) күрсәтә белү. Тест эшләү. | | |
| 26 | М.Мәһдиев. «Без кырыкберенче ел балалары» повесте. | | 14.03 | |
| 27 | М.Мәһдиев. «Без кырык беренче ел балалары» повестен өйрәнүне йомгаклау. Тест. | | 21.03 | |
| 28 | М.Галиев. “Уйна әле” хикәясе. | Әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле уку; укыганны телдән сурәтләпбирә алу. Проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, композиция: әсәр кору алымнарын күрә, аера белү; тема, проблема, идея, вакыйга, күренеш, сюжет, сюжет элементларын дөресбилгеләү. | 4.04 | |
| 29 | Г.Гыйльманов. «Язмышның туган көне» хикәясе. | Әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле уку; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, плантөзи белү. проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба | 11.04 | |
| 30 | Г.Гыйльманов. «Язмышның туган көне» хикәясе. | белү, вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст, конфликт, сюжет, сюжет элементларын күрә, аера белү. | 18.04 | |
| 31-32 | З.Хәким. «Сәер кыз»драмасы. | Драма жанрын һәм аңа хас үзенчәлекләрне тану, әдәби әсәр төрләрен, жанрларын таный, аера, аларга хас үзенчәлекләрне, сәнгати алымнарны таба белү, фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу. Драма әсәрләрен аңлы һәм сәнгатьле укый белү; укыганны телдәнсурәтләп бирә алу. | 25.04<br>2.05 | |
| 33 | Р.Харисның тормыш юлына кыскача күзәтү “Сабантуй”поэмасы | Әдәби әсәрне аңлы һәм сәнгатьле уку; укыганны телдән сурәтләп бирәалу; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, план төзи белү. проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. элементларын күрә, аера белү.Милли бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр турында фикер алышу. | 16.05 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 34 | Р. Фәйзуллин. “Биеклек”, “Туган тел турында бер шигырь”, “Онытма син” шигырьләре. БСҮ. Йомгаклау. Кабатлау. Еллык контроль тест. | Лирик жанрларны тану күнекмәсен үстерү, лирик герой сыйфатларын билгеләү. | 23.05 | |

**Перечень учебно-методических пособий**

Список литературы

I. Основное:

1. Загидуллина Д. Ф. методика преподавания татарской литературы в школе. - Казань: издательство “Магариф", 2000.

2.Литература. 7 класс: учебное пособие для общеобразовательных организаций на татарском языке./Д. М. Абдуллина, Л. К. Хисматова, Ф. Х. Заугарова.- Казань: Тат.кит.издание. Две тысячи четырнадцать

3.Особенности преподавания предмета литературы. Методические рекомендации для педагогических работников,реализующих программы начального,основного, среднего общего образования по татарской литературе/ М. Г. Музафарова.-Казан.- Институт развития образования РТ.- 2014 год

II. дополнительно:

1.Татарский фольклор: учебник для вузов/М. Х. Бакиров.-Казань: Образование, 2008

2.Татарская детская литература: учебное пособие для общеобразовательных школ, средних и высших педагогических учебных заведений/ Л. И. Мингазова, И. Х. Мияссарова.- Казань: издательство “память” Республики Татарстан,2009

3.Анализ литературного произведения: пособие для учащихся средних общеобразовательных школ, преподавателей, студентов педагогических колледжей и вузов/Д. Ф. Загидуллина, М. И. Ибрагимов, В. Р. Аминова.-Казань: Образование, 2005

4.Словарь литературоведения/А. Г. Ахмадуллина.- Казань: Татарское книжное издательство, 1990

5. Хатипов Ф. М. Теория литературы. - Казань:” Образование", 2000.

6. Хаков В. Х. татарский литературный язык. - Казань: Татарское книжное издательство, 1999.

7. Юсупов Р. А. Адап башы-тел.   Казан. КДПУ, 2000.

8. Татарская литература. Начало XX века: лекции, практические занятия, тесты: учебное пособие для вузов/ Т. Ш. Гилязов.-Казань: Образование, 2007

9. Татарская литература начала XX века. Учебник-пособие для учителей средних школ, студентов и старшеклассников. Казань, Татарское книжное издательство, 1982

Список литературы для школьников

1. Ахмадуллин А. хрестоматия из татарской литературы. - Казань: "История", 2002.

2.Болгар, Казань не сходят с языков: легенды и легенды.-Казань: Образование, 2001

3.Татарское народное творчество.- Казань: Татарское книжное издательство, 1988

4.Дастаны.- Казань: издательство “Магариф”, 2001

Интернет сайты: dzalilova/narod. ru., metodisty.ru", sarvarova.ucoz, magarif-uku.rutugan-tel.blogspot.com"p/blog-page_8553.html

**Укыту-методик әсбаплар исемлеге**

**Әдәбият исемлеге**

**I. Төп:**

**1.** Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2000.

**2.** Әдәбият. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы./Д.М.Абдуллина, Л.К.Хисмәтова, Ф.Х. Җәүһәрова.– Казан: Тат.кит.нәшр., 2014

**3**. Әдәбият предметын укыту үзенчәлекләре. Татар әдәбияты буенча башлангыч,төп,урта, гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куя торган педагогик хезмәтләр өчен методик тәкъдимнәр/ М.Г.Мозаффарова.-Казан.-ТР Мәгарифне үстерү институты.-2014 нче ел

**II. Өстәмә:**

1. Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен дәреслек/М.Х.Бакиров.-Казан: Мәгариф,2008
2. Татар балалар әдәбияты: гомуми белем бирү мәктәпләре, урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку әсбабы/ Л.И.Минһаҗева, И.Х.Мияссарова.-Казан:Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты,2009
3. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма/Д.Ф.Заһидуллина, М.И. Ибраһимов, В.Р.Әминева.-Казан: Мәгариф, 2005
4. Әдәбият белеме сүзлеге/А.Г.Әхмадуллина.-Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1990
5. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. – Казан: “Мәгариф”, 2000.
6. Хаков В.Х. Татар әдәби теле.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1999.
7. Юсупов Р.А. Әдәп башы – тел. Казан. КДПУ, 2000.
8. Татар әдәбияты. XX гасыр башы: Лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар: Югары уку йортлары өчен уку әсбабы/ Т.Ш.Гыйлаҗев.-Казан: Мәгариф, 2007
9. XX гасыр башы татар әдәбияты. Урта мәктәп укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен дәреслек-кулланма. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1982

**Укучылар өчен тәкъдим ителә торган әдәбият исемлеге**

1. Әхмәдуллин А. Татар әдәбиятыннан хрестоматия. – Казан: “ТаРИХ”, 2002.
2. Болгар, Казан төшми телләрдән: Риваятьләр һәм легендалар.-Казан: Мәгариф, 2001
3. Татар халык иҗаты.-Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1988
4. Дастаннар.-Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2001

**Интернет сайтлары**: dzalilova/narod.ru., metodisty.ru›, sarvarova.ucoz, magarif-uku.rutugan-tel.blogspot.com›p/blog-page_8553.html

**7 нче сыйныфта әдәбияттан укучыларның белемнәрен бәяләү нормалары**

Тикшерү-бәяләү укучыларның әдәбияттан белемнәрен, аерым темаларның, әсәрләрнең, язучы иҗаты һәм әдәби чорларның үзләштерелү дәрәҗәсен, укучының иҗади һәм логик фикерләү сәләтен, теге яки бу әсәргә шәхси мөнәсәбәтен, карашын җиткерү осталыгын, аны мөстәкыйль анализлау дәрәҗәсен, укытуның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген ачыклау өчен кулланыла.

**Уку күнекмәсе ничек бәяләнә?**

Уку күнекмәсен тикшергәндә, мөгаллим сезнең ни дәрәҗәдә дөрес, йөгерек, сәнгатьле һәм аңлап укуыгызга игътибар итә.

Әдәби әйтелеш кагыйдәләрен саклап, текстны хатасыз итеп уку дөрес уку дип атала. Укучы аваз, иҗек һәм сүзләрне кабатламыйча, аларны төшереп калдырмыйча, урыннарын алыштырмыйча, грамматик формаларын бозмыйча һәм дөрес әйтелешкә карата куела торган иң төп таләпләргә җавап бирерлек дәрәҗәдә укырга тиеш.

Йөгерек уку - укыганның эчтәлеген аңлы рәвештә зиһенгә алуны тормышка ашырырга ярдәм итүче уку тизлеге.
7 нче сыйныфта - 80-125 сүз
Игътибар итегез: укуның төп максаты - текстның дөрес укылуына һәм эчтәлеген аңлауга ирешү. Эчтән уку тизлеге, кычкырып уку белән чагыштырганда, 5-7 нче сыйныфларда - 40-50 процентка, ә 8-9 нчы сыйныфларда 60 процентка югарырак булырга тиеш.

Сәнгатьле уку текстның эчтәлеген аңлап, автор әйтергә теләгән фикер, хис-тойгыларны тавыш, басым һәм башка барлык фонетик чараларны дөрес кулланып укый алуны белдерә.

Аңлап уку, ягъни текстның төп эчтәлеген аңлау һәм аңа карат үз карашыңны яки мөнәсәбәтеңне белдерә алу сәнгатьле укуга ирешүнең төп шарты булып тора. Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген тулаем аңлап, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп, әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес интонация һәм басым белән тиешле тизлектә укыйсыз, укытучының текст эчтәлегеннән чыгып бирелгән сорауларына төгәл җавап бирәсез - "5"ле.

Таләп ителгән күләмдәге текстны тиешле тизлектә укыйсыз, укытучының сорауларына төгәл җавап бирәсез, ләкин кайбер сүзләрнең укылыш үзенчәлекләре орфоэпик нормаларга туры килми, сөйләмнең структур бүленешендә кайбер хаталарыгыз бар, интонацион яктан 1-2 төгәлсезлек җибәрәсез - "4"ле.

Уку тизлеге тиешле нормада түгел, текстны аңлыйсыз, әмма сорауларга биргән җавапларыгызда төгәлсезлекләр җибәрәсез, уку барышында 3-4 фонетик, 2-3 орфоэпик хата ясадыгыз, интонацияне төгәл бирмисез - "3"ле.

Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген аңламыйсыз, эчтәлек буенча бирелгән сорауларга өлешчә генә җавап бирәсез, тиешле тизлектә уку

күнекмәләрегез юк, фонетик, орфоэпик, интонацион хаталар текст эчтәлеген аңлауга комачаулый - "2"ле.

## Сөйләм күнекмәсе ничек бәяләнә?

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча логик яктан эзлекле һәм эчтәлеге ягыннан тулы монологик сөйләм төзи аласыз, бирелгән әсәр яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора беләсез - "5"ле.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча логик яктан эзлекле, әмма эчтәлеге ачылып бетмәгән монологик һәм диалогик сөйләм өчен "4"ле аласыз.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча логик яктан эзлекле итеп сөйли белмисез, эчтәлекне ачып бетерә алмыйсыз, әңгәмәдә өстәмә сораулар бирелгәндә генә катнашасыз - "3"ле.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән темага монолог та, диалог та төзи алмыйсыз - "2"ле.

## Анализ күнекмәләре һәм теоретик белемнәрегез ничек бәяләнә?

Әсәрне анализлау яки чорга характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлап, урынлы кулланасыз, анализыгыз нигезле, җавабыгыз теоретик яктан югары оештырылган - "5"ле.

Әсәрне анализлау яки чорга характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлап та аларны куллану барышында аерым төгәлсезлекләр җибәрәсез, анализ эчтәлек сөйләүгә "борыла" - "4"ле.

Әсәрне анализлау яки характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләр кулланасыз, әмма алар күренешкә туры килми, хаталар ясыйсыз; анализ әсәр эчтәлеген кабатлап сөйләүдән генә гыйбарәт - "3"ле.

Әсәрне анализлау яки характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләрдән мәгълүматсыз булуыгыз күренә, аларны җавабыгызда кулланмыйсыз, анализ бөтенләй юк - "2"ле.

## Сорауларга җаваплар язу ничек бәяләнә?

Эшләрегезне бәяләгәндә, укытучы җавабыгызның тулы, төгәл, дөрес булуына, сөйләмегезнең стилистик яктан камил, орфографик һәм пунктуацион яктан грамоталы булуына игътибар итә.
Барлык сорауларга да дөрес җавап бирдегез (1 сөйләм хатасы яки 1 пунктуацион хатагыз булырга мөмкин) - "5"ле.

Сорауларга дөрес җавап бирдегез, ләкин 2 сөйләм хатасы, 3 орфографик, 2 пунктуацион хата яки 2 сорауга җавап язганда, төгәлсезлек җибәрдегез - "4"ле.
Язма эштә сорауларга җавап бирә белү күнекмәсе сизелә, 3 сөйләм хатасы, 4 орфографик, 5 пунктуацион хатагыз бар - "3"ле.
Җавапларыгызның яртысы дөрес түгел, сөйләм хаталарыгыз 3 тән артык, 5 орфографик, 6 пунктуацион хатагыз бар - "2"ле.

**Сочинение язуга таләпләр**

Сочинение язганда, укучы өйрәнелгән зур күләмле әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларга; шуларга бәйләп, язучы яшәгән, әсәрнең нигезенә алынган чорга, ул вакыттагы тарихи һәм иҗтимагый шартларга; шул чорга хас әхлакый нормаларга; әсәрдә бирелгән геройларга һ.б. карата мөнәсәбәтен белдереп, үзенең әдәби язма текстын "тудыра".
Ике сәгать дәвамында сыйныфта язылган сочинениенең күләме түбәндәгечә билгеләнә:
7 нче сыйныфта - 2-3 бит.
Сочинениене озын итеп язу төп максат түгел, чөнки, билге куелганда, беренче чиратта, язмада теманың тулы һәм эзлекле итеп ачылуына, тел байлыгына, хаталарның булмавына, грамоталылык дәрәҗәсенә игътибар бирелә.
Хаталар поляда күрсәтеп барыла. Югары сыйныфларда хата төзәтелми, хаталы урын астына сызып күрсәтелә. Язма эштән соң беренче юлда укытучы ялгышларның санын күрсәтә: башта орфографик (вертикаль сызык рәвешендә "I"), аннан соң пунктуацион ("V" рәвешендә) һәм стилистик ("С" рәвешендә) хаталар санын яза. Алар ике нокта аша (1:3:2 рәвешендә) яки хәрефләр белән тамгаланып (О-1, П-3, С-2 рәвешендә) күрсәтелә. Моннан тыш сочинениедә логик (Л рәвешендә күрсәтелә) һәм фактик хаталар (Ф рәвешендә) да билгеләнә ала. Логик хаталарга орфографик һәм грамматик кагыйдәләрне бозу нәтиҗәсендә мәгънә төгәлсезлегенә китерә торган кимчелекләр керә. Әсәр исемен, вакыйгаларны, чорны (гасыр, ел, ай, көн һ.б.); персонажларның (герой, катнашучы яки аның турында нинди дә булса фикер әйтүче кешенең) исем һәм фамилияләрен, алынган цитаталарның чыганагын бутау; техник төгәлсезлекләр фактик хатага санала.
Сочинение ике билге белән бәяләнә: беренчесе - эшнең эчтәлеге һәм теленә, икенчесе грамоталылыкка куела.
Сочинениенең эчтәлеге һәм теле түбәндәгечә бәяләнә:
Эчтәлек темага туры килә; язмада фактик ялгышлар юк; эзлекле язылган; теле бай, образлы; стиль бердәмлеге сакланган - "5"ле.
Язманың эчтәлеге темага, нигездә, туры килә, ул дөрес ачылган; 1 фактик хата җибәрелгән, хикәяләү эзлеклелегендә артык әһәмияте булмаган төгәлсезлек сизелә; тулаем алганда, теле бай, образлы; стиль бердәмлеге сакланган - "4"ле.
Эчтәлекне бирүдә мөһим читләшүләр бар: ул, нигездә, дөрес, ләкин фактик төгәлсезлекләр очрый, хикәяләү эзлекле түгел; теленең ярлылыгы сизелеп тора; синонимик сүзләрне аз куллана, бертөрлерәк синтаксик төзелмәләр файдалана, образлы түгел, сүз куллануда ялгышлар җибәрә; стиль бердәмлеге сакланып җитмәгән - "3"ле.
Тема ачылмаган; фактик төгәлсезлекләр күп; планга туры килми, эзлеклелек бозылган; теле ярлы; сүз куллану ялгышлары еш очрый; стиль бердәмлеге юк - "2"ле.
Грамоталылык түбәндәгечә бәяләнә:
1 орфографик (пунктуацион яисә грамматик) ялгыш бар - "5"ле.

2 орфографик, 2 пунктуацион һәм 2 грамматик ялгыш бар - "4"ле.
3 орфографик, 3 пунктуацион һәм 3 грамматик ялгыш бар - "3"ле.
7 орфографик, 7 пунктуацион һәм грамматик ялгышлар бар - "2"ле.